КАРАР
Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы
Карамалы авыл җирлеге Советы

Карамалы авылы №173 «20» июль 2020 ел

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Карамалы авыл җирлеге Советының 2016 елның 01.06. 33 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Карамалы авыл җирлеге муниципаль милкен хосусыйлаштыру тәртибе турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында ( 28.10.2016 №41, 19.09.2017 №66, 06.02.2018 №85, 28.12.2019 №153 карарлар редакциясендә)

2009 елның 2 августындагы 301-ФЗ номерлы «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» Федераль закон нигезендә

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы
Карамалы авыл җирлеге Советы карар итте:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Карамалы авыл җирлеге Советының 2016 елның 01.06. 33 номерлы карары белән расланган, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Карамалы авыл җирлеге муниципаль милкен хосусыйлаштыру тәртибе турындагы нигезләмәгә (28.10.2016 №41, 19.09.2017 №66, 06.02.2018 №85, 28.12.2019 №153 карарлар редакциясендә) түбәнәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 7 бүлекнең 3 пунктында "федераль закон белән билгеләнгән минималь хезмәт хакы күләменнән илле мең тапкыр артып китә" сүзләрен "федераль закон белән билгеләнгән минималь хезмәт хакы күләменнән 10 тапкыр артып китә" сүзләренә алмаштырырга;

1.2. 11 бүлекнең 3 абзацында "федераль закон белән билгеләнгән минималь хезмәт хакы күләме илле мең тапкырдан артып китә" сүзләрен "Ачык җәмгыять устав капиталының федераль закон белән билгеләнгән минималь күләменнән 50 тапкырдан артык"сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны "Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында" түбәндәге веб -адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Азнакай муниципаль районының мәгълүмат сайтында "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча урнаштырырга: http://aznakayevo.tatarstan.ru.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны законлылык, хокук тәртибе, депутат этикасы һәм җирле үзидарә мәсьәләләре буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Рәис А.Р. Ногманов